РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ»
Переулок Больничный, дом 6,
пгт. Рыбная Слобода, 422650

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
«МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
Хастаханә тыкрыгы, 6 нчы йорт,
Балык Бистәсе штп., 422650

Тел.: (8-84361) 2-21-92, факс: (8-84361) 2-21-26. E-mail: sloboda.ege@rambler.ru, sloboda.filial@mail.ru

**Балык Бистәсе муниципаль районы “ Балык бистәсе 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хәбибуллина Рәзилә Нурмый кызын татар теле һәм әдәбияты укытучыларының “Туган тел” Бөтенрәсәй мастер- класс бәйгесенә тәкъдим итү кәгазе**

Хәбибуллина Рәзилә Нурмый кызы 1975нче елның 20 нче декабрендә Балык Бистәсе районы Күгәрчен авылында туган. Югары белемле, 1999 нчы елда Казан дәүләт педагогия университетының татар филологиясен тәмамлаган.

| № | Эш урыны | Вазифа | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре Яңа Савин районы “Татар телендә белем бирүче 13нче гимназия” | Башлангыч сыйныф укытучысы | 15.08.1996 – 14.09.1998 |
| | Казан шәһәре Яңа Савин районы “Инглиз телен тирәнтен өйрәтүче 165нче урта гомуми белем мәктәбе | Татар теле һәм әдәбияты укытучысы | 16.09.1998 – 19.08.1999 |
| 2 | Балык Бистәсе районы “ Балык Бистәсе 2нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” МБГБУ | Татар теле һәм әдәбияты укытучысы | 28.08.1999- |

Квалификация категориясе: беренче
Эш стажы: 22 ел
Эш шартлары: 2018-2019нчы елда – татар теле, татар әдәбияты дәресләре, 3в,4б,7а,7б (татар төркемнәре), театр түгәрәге.
Хәбибуллина Рәзилә Нурмый кызы педагогик хезмәт нәтиҗәләре өчен түбәндәге мактау кәгазьләре белән бүләкләнде:
-“Ел укытучысы -2009” бәйгесе призеры Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесы грамотасы; 2009
- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесы Мактау Грамотасы; 2010
- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесы Грамотасы; 2011

- Г.Тукайның тууына 126 ел тулуга багышланган Татарстан Республикасы укытучылары һәм укучыларының “Илһам чишмәсе”исемле республика әдәби-иҗат бәйгесе өчен Татарстан Республикасы Мәгариф Министрлыгының III дәрәҗә дипломы; 2012
- Рафаил Газиз исемендәге төбәкара әдәби бәйгедә призер укучы әзерләгән өчен ТР Мәгариф министрлыгының рәхмәт хаты, 2018
- “Ел укытучысы -2019” бәйгесе призерына Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге муниципаль казна учреждениесы” Мактау Грамотасы; 2019.

Хәбибуллина Рәзилә Нурмый кызын хезмәттәшләре һәр эшне җиренә җиткереп, иҗади якын килеп башкаруы өчен яраталар. Ул бик зур оештыру сәләтенә ия, һәрвакыт яңалыкка омтыла һәм укучылардан да шуны таләп итә.

Рәзилә Нурмый кызы үзенең педагогик эшчәнлегендә алдынгы технологияләргә таянып эшли. Ул “Ел укытучысы-2009” Бөтенрәсәй бәйгесенең муниципаль этабында 3нче урынга, 2019нчы елда призер исеменә лаек булды.

“Балык Бистәсе 2нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе” МБГБУ укытучысы Хәбибуллина Рәзилә Нурмый кызының уңай эш тәҗрибәсе республикакүләм уртаклашуга лаек дип табыла, Бөтенрәсәй Туган тел һәм әдәбияты укытучыларының “Туган тел” мастер-класс бәйгесендә катнашырга тәкъдим ителә.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының “Мәгариф
бүлеге” муниципаль казна
учреждениесы җитәкчесе И.М.Садыйков